БАЛАЛАР ЖУРНАЛЫ • ДЕТСКИЙ ЖУРНАЛ • CHILDREN'S MAGAZINE

№6 2016

Салават күпере



ISSN 0868-4545



ИЮНЬ

ДҮШӘМБЕ	СИШӘМБЕ	ЧӘРШӘМБЕ	ПӘНҖЕШӘМБЕ	ҖОМГА	ШИМБӘ	ЯКШӘМБЕ
		1 Халыкара балаларны яклау көне	2 Дөрес туклану көне	3 Кояшта кызыну көне	4 Матурлык көне	5 Әйләнә-тирәне саклау көне
6 А.С. Пушкин көне	7 Социаль хезмәткәрләр көне	8 Океаннар көне	9 Халыкара дуслар көне	10 Тормышны сөючеләр көне	11 Югары мода көне	12 Россия көне
13 Булавканы уйлап табу көне	14 Донорлар көне	15 Бөтендөнья җил көне	16 Рәхәтләнеп көлү көне	17 Серләшү көне	18 Ягымлылык көне	19 Халыкара әтиләр көне
20 Туйлар көне	21 Елның иң озын көне	22 Аңлашу көне	23 Халыкара олимпиадалар көне	24 Су коену көне	25 Балыклар көне	26 Теш щеткасын уйлап тапкан көн
27 Яшьләр көне	28 Яңа уй-фикерләр көне	29 Телевизор пультының туган көне	30 Пионнар көне			

«SK» КАЛЕНДАРЕ

© «Салават күпере», 2016 ел.

Безнең VKontakte битенә «Салават күпере» журналы белән төшкән фотоңны куй һәм тавыш җый!

МИН «САЛАВАТ КҮПЕРЕ»Н УКЫЙМ!

Солтан, 7 яшь, Әтнә.

Айсылу, 9 яшь, Рания, 6 яшь, Казан.

Әмир, 3 яшь, Апас.

Әлфинә, 10 яшь, Апас.

Нәргизә, 7 яшь, Камилә, 4 яшь, Минзәлә.

Зәринә, 9 яшь, Апас.

Ләбиб ЛЕРОН

ГАЕТ КӨНЕ

Җылы, йомшак ятакларында изрәп яткан игезәк оныклары Айдар белән Хәйдәрне Галим бабай бүген бик иртә уятты.

– Балалар, уяныгыз! Бәйрәм көнне озак йокламыйлар, – диде ул.

«Бәйрәм» сүзен ишетүгә, балалар урыннарыннан сикереп торды.

– Хәерле иртә, балалар! Ураза бәйрәмебез мөбарәк булсын! – диде бабай. – Алмаш-тилмәш бик һәйбәтләп юынып чыгарсыз. Гает намазына пакьләнеп бару мәслихәт, – диде ул.

– Аннан соң мәчеткә барабыз, иеме, бабакай? – диде Айдар, күзләрен челт-челт йомгалап. – Әллә Гает коймагы ашыйбызмы?

– Гает коймагы белән мәчеттән кайткач сыйланырбыз. Әнә, әбиегез, коймагым тәмле генә була күрсен инде берүк, дия-дия, күптәннән хәстәрләнеп йөри...

Мәчеткә якынлашканда, Айдар да, Хәйдәр дә койма буенда чүгәләп утырган яисә тезелешеп басып торган сәләмә киемле әби-бабайларга игътибар иттеләр. Араларында аяксыз яки кулсыз кешеләр дә бар иде.

– Болар – ачлы-туклы яшәп көн итүче фәкыйрьләр, ярдәмгә мохтаҗ Ходай бәндәләре, – диде бабалары малайларның сораулы карашын тоеп. Әйдәгез, фитыр садакасы биреп, сөендерик әле үзләрен...

Намаз укыганда өлкәннәр үзләрен ни рәвешле тотсалар, Айдар белән Хәйдәр дә шуны кабатладылар. Хәзрәтнең Гает намазын укыганнан соң сөйләгән вәгазен дә малайлар бик бирелеп тыңлады.

Балалар, җәяү кайтканда, бер-берсен бүлдерә-бүлдерә, бәйрәмнән алган тәэсирләрен бабалары белән уртаклаштылар. Йөзләрендә шатлык нурлары уйнаган оныкларының шулай дәртләнеп, очынып-очынып үзара гәпләшеп кайтулары Галим бабайның күңеленә, җаны-тәненә җиңелчә бер рәхәтлек һәм ләззәт бирә иде.



Рәссам Әлфия ЙОСЫПОВА



НӘНИ АПУШ ЮЛЫ

Дуслар, хәтерләсәгез, журналыбызның февраль санында «Нәни Апуш юлы» бәйгесен игълан иткән идек. Аның шартлары буенча, Габдулла Тукай музеена барып, аның тормышына һәм иҗатына бәйле сорауларга җавап табарга кирәк иде.

Республикабызда яшәүче балаларның бөек шагыйребез турында яхшы белүләре шатландырды. Бәйгегә 300 эш кабул ителде, шулар арасында 90 укучыбыз дөрес җаваплар җибәрде!

24 май көнне Казанда җиңүчеләрне бүләкләү тантанасы узды. Беренче бүләк – Татарстан Милли музееннан Е.А.Боратынский музеена экскурсия булса, икенчесе – «Салават күпере» журналының махсус бүләге – «Ривьера» аквапаркына билет һәм, әлбәттә, истәлекле дипломнар. Котлыйбыз!

«НӘНИ АПУШ ЮЛЫ» БӘЙГЕСЕ ҖИҢҮЧЕЛӘРЕ:

КАЗАН

Адель Әхмәтшин
Азалия Мөхәмәдиева
Азамат Шәмсиев
Азиз Бегишев
Айзилә Сабирова
Айнур Зарифов
Айрат Абдуллин
Алия Гыйбадуллина
Алмаз Миңнебаев
Альмира Зыятдинова
Асилә Закирова
Әдилә Денмөхәммәтова
Әдилә Мингалиева
Әлфия Кәримова
Әмир Габдуллин
Әскәр Богданов
Булат Фаизов
Гадел Зыятдинов
Җәмил Кашапов
Зәмирә Абдракипова
Зәмирә Шәрәфиева
Зилә Вәлиуллина
Зилә Миңнебаева
Зәринә Шәрипова
Зөлхиҗә Салихова
Ибраһим Миңнебаев
Илүзә Мостафина
Камилә Даутова
Камилә Гайнетдинова
Камилә Гыйләҗиева
Камилә Гобәева
Камил Гайнетдинов
Камил Низамов
Кәрим Мөхетдинов
Кәрим Насыйбуллин
Кәрим Сабирҗанов
Нурия Әлмөхәмәтова
Рамзан Абдрахманов
Рөстәм Газизов
Самат Вахит
Самирә Вафина
Фәридә Шәрәфиева





ЧИСТАЙ

Рамил Гайфетдинов

БИЕКТАУ

Рифат Мәликов

АКТАНЫШ

Әдилә Шәмсиева

МАМАДЫШ

Камилә Хәбибуллина
Кәрим Сәләхеев

БАЛЫК БИСТӘСЕ

Зифа Зәйнуллина
Булат Мөбәрәкшин
Латифә Бакирова

ПИТРӘЧ

Ясминә Әлмиева

НОРЛАТ

Адель Мортазин
Әлинә Миннәбетдинова

САРМАН

Алия Закирова
Ләйсән Хафизова
Нияз Гыйльметдинов
Рузил Шәмсемөхәмәтов

САБА
Азалия Зәйнәгыева
Данис Әхмәтҗанов
Зәлия Вәлиева
Илсинә Яруллина

ӘЛМӘТ
Илсур Мифтахов

КАЙБЫЧ
Ләйсән Абдрахманова

КУКМАРА
Әдилә Хәнәфиева
Зилә Галиева
Илназ Галәветдинов
Рузилә Нуриева

БАЛТАЧ
Айзилә Гомәрова
Алинә Мөҗипова
Гайшә Камалиева
Ислам Гатауллин
Камилә Закирова
Камилә Мөхәммәдиева
Мәликә Гәләүтдинова
Сөләйман Закиров

МӨСЛИМ
Ришат Хөснимәрдәнов
Фәрхәд Гәрәев

АРЧА
Алсу Шакирова
Әмир Кашапов
Гүзәл Вәлиева
Инсаф Җәләлиев
Камилә Шәрипова

ЯШЕЛ ҮЗӘН
Илсөяр Зинурова

ӘТНӘ
Гөлия Кәлимуллина

ТЕЛӘЧЕ
Гөлсем Биккинина
Ислам Бәдриев

БУА
Алинә Сәмитова
Гайшә Җамалетдинова

ТӘТЕШ
Гүзәл Биктимерова
Камилә Нургалиева

ӘНИЛӘР ҺӘМ НӘНИЛӘР

Дускай, син тәм-томнар яратасыңмы? Әлбәттә! Әниең сине һәрвакыт тәмле әйберләр белән сыйлаганын да беләбез. Нәкъ менә синең кебек тәмлетамаклар һәм әниең шикелле оста хуҗабикәләр өчен без «Әниләр һәм нәниләр» дигән гаилә рецептлары бәйгесен игълан иткән идек. Ниһаять, syuyumbike.ru сайтында онлайн тавыш бирү нәтиҗәләре – җиңүчеләр дә билгеле. Таныш булыйк – үрнәк алыйк!



Ясминә Галләмова
әнисе Регина белән
(Азнакай)



Әдилә Хәнәфиева
әнисе Рузия белән (Кукмара)



Илсөяр Зинурова
әнисе Рәсимә белән
(Яшел Үзән)

Бәйрәм тантанасыннан фотолар белән salavatkupere.com сайтында таныша аласыз.

Игътибар! «Ел тәрбиячесе» бәйгесенә salavatkupere.com сайтында тавыш бирү башланды.

ҺӘР РӘТТӘ АРТЫК ӘЙБЕРНЕ БИЛГЕЛӘ. АЛАРНЫ НӘРСӘ БЕРЛӘШТЕРӘ?



ЧҮПЛӘРНЕ ДӨРЕС САВЫТКА ТАШЛА. НИ ӨЧЕН ЧҮПЛӘРНЕ АЕРУ КИРӘК?









ДӨРЕС ҖӨМЛӘЛӘР КИЛЕП ЧЫКСЫН ӨЧЕН, ТӨШЕП КАЛГАН РӘСЕМНӘРНЕ ТАП.








РОССИЯ ГЕРБЫНДА ? ЯСАЛГАН


ИЛЕБЕЗНЕҢ ӘЛӘМЕНДӘ ? ТӨСЛӘР БАР




РОССИЯ ? МАТЕРИГЫНДА УРНАШКАН

КӨНЬЯК АМЕРИКА

АВСТРАЛИЯ


ЕВРАЗИЯ


12 ИЮНЬ

9 МАЙ

1 ГЫЙНВАР


РОССИЯ КӨНЕ ? БИЛГЕЛӘП ҮТЕЛӘ

НОКТА БУЛГАН ҖИРЛӘРНЕ ГЕНӘ БУЯ. ЙӘ, НӘРСӘ КИЛЕП ЧЫКТЫ?



Җаваплар salavatkupere.com сайтында.



Альбина ИГЪЛАМОВА,
Казан, 90 нчы гимназия,
3 нче сыйныф.



Настя БРОННИКОВА,
Бөгелмә,
14 нче прогимназия, 6 яшь.



Әминә МӘХМҮТОВА,
Сарман,
6 яшь.



Ильяс ХАҖИЕВ,
Саба, Байлар Сабасы,
1 нче гимназия, 7 яшь.



Гүзәл ФӘЙЗРАХМАНОВА,
Арча, Иске Ашыт,
3 нче сыйныф.




Камилә ХӘКИМҖАНОВА,
Әтнә, Яңа Шашы,
2 нче сыйныф.



Гөлинә СӨНГАТУЛЛИНА,
Арча, Шушмабаш,
4 нче сыйныф.



Ралинә МОРЗАХАНОВА,
Казан, 62 нче мәктәп,
6 нчы сыйныф.



Алинә КУНАФИЕВА,
144 нче мәктәп,
11 яшь.


СИНЕҢ РӘСЕМНӘРЕҢНЕ ДӘ КӨТЕП КАЛАБЫЗ!




Хәзинә

Гаиләбездә һәркем китап укырга ярата. Дүрт яшемдә үзем дә укый башладым. Укырга мине әнием өйрәтте. Минем өчен китап җанлы кебек. Китап уку бик рәхәт. Укыган вакытта әсәр геройлары белән сөйләшәм дә алар турында уйланам. Татарча китапларны да аңлап укый алам. Китапсыз тормыш кызык та булмас иде кебек. Китап – иң зур хәзинә бит ул. Аны бернинди компьютер да, телевизор да, интернет та алыштыра алмый!

Снежана ЩЕРБАКОВА,
Кукмара, А.М.Булатов исемендәге лицей,
6 нчы сыйныф.





Җил һәм Капка

Борын-борын заманда яшәгән, ди, бер Капка белән Җил. Алар бик дус булганнар. Җил гел шаярырга яраткан, ә Капка тыныч кына аның белән уйнаган. Капка Җилне гел тәртипле булырга, артыгын шаярмаска өндәгән, ләкин Җил аның сүзләренә колак салырга яратмаган.

Беркөнне Җил ялгыш кына Капканы шапылдатып япкан һәм Капканың бер тактасы кәкрәеп, ямьсезләнеп калган. Капканың моңа бик ачуы килгән. Җил гафу үтенгән, ләкин Капка аны кичермәгән, чөнки күпме генә тырышмасын, күпме генә аны төзәтмәсеннәр, Капканың элеккеге матурлыгы кире кайтмаган. Җил әле дә аннан гафу сорап, Капканың бер алдына, бер артына чыгып карый икән, ләкин Капка гына бикләнә дә, ачылмый, ди.

Менә шулай, дуслар, уйнаганда да сак, бер-береңә игътибарлы булырга кирәк.

Динә НУРГАЛИЕВА,
Актаныш, Пучы төп гомуми белем бирү мәктәбе,
1 нче сыйныф.

Рәшит БӘШӘР

КЫЗЧЫК

Өй рәсеме ясады –
Тәрәз төпләре гөлле.
Зәңгәрсу пәрдәләргә
Алсу пәрдәләр элде.

Диван ясады аннан,
Ясады аннан өстәл.
Диванына ямь-яшел
Мендәрләр куйды өстәп.

Келәм җәйде идәнгә,
Келәмгә төште якты.
Шаян песи баласы
Диванга менеп ятты.

Песинең мыегына
Күбәләк килеп кунды.
Күбәләкле, песиле
Тылсымлы бер өй булды.

Йоклап яткан песинең
Кояш төште күзенә...
Рәсемгә ятып кызчык
Йоклап китте үзе дә.

Рашит БАШАР

ДЕВОЧКА РИСУЕТ

Девочка рисует дом
С крышей, дверью и окном.
Шторки ярко голубые,
На окне горшок с цветком.

Она нарисовала стол,
Стул, диванчик и буфет.
Для подушек на диване
Выбрала зелёный цвет.








Она расскрасила ковёр.
Солнце заглянуло в дом:
По ковру запрыгал лучик
Словно на лугу цветном.

Пришёл котёнок-озорник
На диван забрался, лёг,
И на усики котёнка
Опустился мотылёк.

Смотрите: с бабочкой, с котом
Стал волшебным этот дом!

От уснувшего котёнка
Луч прошёлся до стола...
Опустив на стол головку,
Сладко девочка спала.

Перевод
Талии ШАРАФИЕВОЙ



Rashit BASHAR

A LITTLE GIRL

Drew a nice house –
The window-sills with flowers.
She covered blue curtains
With sweet pink valance.

Then she placed a soft sofa
And put a table next to it,
Emerald-green pillows
Will make it comfortable to sit.

A carpet was laid on the floor
Warm light beamed
on the door.
A playful warm kitty
Jumped on the sofa gently.

A sweet colorful butterfly
Sat down on the cat's eye.
What a magic little house
With a cat and butterfly!

Transparent rays of the sun
Tickled the purry sleepy cat...
Our girl started falling asleep
With the picture in her hands.

Translation
Dilyara SHARIFULLINA

Рәссам Әлфия ЙОСЫПОВА

ШАТЛЫК ТАРАТУЧЫЛАР



Дустым, «Салават күпере» журналы өеңә ничек килеп җиткәне турында уйланганың бармы? Ул бит, озын юллар үтеп, республикабызның төрле төбәкләрендә яшәүче дусларына барып ирешә һәм аларны сөендерә.
Журнал-гәҗитләр, хат-посылкалар тарату – барысы да почта хезмәте аша башкарыла. Җәй көне алар үз бәйрәмнәрен билгеләп үтә. Почта кайчан барлыкка килгән һәм ничек эшли икән?


Башта хәбәрләрне җәяү йөреп, соңрак атка атланып җиткергәннәр. Язу барлыкка килгәч, хатлар язма рәвештә йөри башлаган. Беренче шундый хәбәр 5 мең еллар элек Месопотамиядә балчык белән язылган. Хәбәрләр тарату эше Борынгы Мисырда зур үсеш ала, шуңа хәзерге заман почта элемтәләренә шунда нигез салынган дип тә саныйлар.

Элек хатларны почта күгәрченнәре аша да тапшырганнар. Бу кошлар кая гына җибәрсәләр дә, кире әйләнеп кайта алганнар. Алар сугыш вакытында төп хәбәр таратучылар булып торган.



Зур шәһәрләрдә хат ташучылар тукталып алу өчен махсус урыннар булган. Аларны пост дип атаганнар. Почта сүзе дә шуннан килеп чыга.

16-17 нче гасырларда Европа илләрендә үзәк патшалык почталары булган. Монда хатларны карета белән ташыганнар. Берәр авылга шундый карета килү зур вакыйга саналган. Бу турыда хат ташучы мөгез быргы кычкыртып хәбәр биргән.



Бүгенге көндә илебездә почта хезмәтен «Почта России» дип исемләнгән оешма башкара. Ул үзенә 87 филиал, 42 мең почта бүлекчәсен сыйдыра. Ел саен Россиядә яшәүчеләр 1,7 миллиард хат, 54 миллион посылка җибәрә.
Безнең республикабызда «Татарстан почтасы» почта элемтәсе идарәсен Регина Кузнецова җитәкли. Аның кул астында көн саен сиңа журналны алып килеп бирүче тырыш хат ташучы абый-апалар да эшли.

Исәнмесез, «Салават күпере» журналының яшь укучылары!

Сезгә бүгенге көндә почта бүлекчәләренең ничек эшләве турында сөйлисем килә.

Мәсәлән, сез үзегезнең Мәскәүдә яши торган дустыгызга хат яздыгыз, ди. Почтага бардыгыз, конверт, марка алып, ябыштырып, барысын да дөрес тутырып, аны почта әрҗәсенә салдыгыз. Менә шуннан хатның зур сәяхәте башлана инде. Башта ул шундый ук хатлар һәм открыткалар янына төшә, бер-берсе белән танышырга да өлгерәләр. Алар бик күп, әрҗәгә колакны куеп тыңласаң, кыштырдаган тавышларын да ишетеп була! Бераздан хатларны операторлар капчыкларга тутырып аралау үзәгенә озата. Үзәктә аларны төрле төбәк, шәһәрләр буенча аералар. Шулай итеп сезнең хат Мәскәүгә бара торганнары янына эләгә. Зур, сары контейнерларга тутырып, аларны почта вагоннарына төйиләр. Хат, открытка, кечкенә бандерольләр һәм зур посылкалар егерме сәгатькә якын тимер юлда булып Мәскәү артына барып җитә.

Монда аларны яңадан аралау үзәгенә озаталар. Бу үзәктә инде эшне автоматлаштырылган зур машиналар башкара. Шулай итеп хатлар төрле почта бүлекләренә бүленә. Аларны зур капчыклар һәм контейнерлар белән зәңгәр почта машиналарына төяп, Мәскәүдәге почта бүлегенә җибәрәләр.

Хатларны түземсезлек белән хат ташучылар көтеп тора. Бу абый-апалар аларны сумкаларына тутырып, таратырга ашыгалар. Подъезд яки капкалы өйләргә килеп, хат һәм открыткаларны почта әрҗәсенә салалар.

Синең хатың дустыңа барып җиткәнче менә нинди озын юл үтә!

Бу ел ахырында Казанда аэропорт янында бик зур почта үзәге ачылачак дип көтелә. Монда Мәскәүдәге кебек зур машиналар эшләячәк. Экскурсиягә килми калмагыз!

Ә мин, сезгә уңышлар теләп, саубуллашам!




Кузнецова
Регина Викторовна








Дускай, син дә «Салават күпере» журналына «Хат язам» дигән тамга белән чып-чын хат язып, аны почта аша җибәр. Хатта уңышларың, хыял-теләкләрең турында язсаң әйбәт булыр. Иң матур хатлар журнал битләрендә урын алачак.




КҮЧТӘНӘЧ




Без – «Күчтәнәч»ләр Казан шәһәренең Совет районында 67 нче номерлы бик матур балалар бакчасында тәрбияләнәбез. Һәр көнебез тылсымга, искиткеч маҗараларга, яңа белемнәргә бик бай. Бакчабыздагы айкидо, бию түгәрәге, инглиз теле, изо-дизайн студиясе, логик фикерләү түгәрәкләренә йөрү безне һәрьяктан үстерә. Һәм, әлбәттә, туган татар телебезне дә яратабыз. Татар телен шөгыльләр, журнал-китаплар, уеннар, шигырь, хикәя, әкиятләр аша өйрәнәбез. Сөмбелә, Каз өмәсе, Нәүрүз, Карга боткасы, Сабантуй кебек милли чараларда бик теләп катнашабыз.

Арабызда иң оста җитәкче апабыз – Ильмира Әсәт кызы Әхмәтҗанова. Ул «Күчтәнәч»ебезне гөл-чәчәккә күмде. Интерактив такталар, мультмедиа проекторлары, музыка, спорт залы, тылсымлы бүлмәләребез дә аның тырышлыгы белән булдырылды. Киләчәктә дә бердәмлектә, дуслыкта яшик!

















«Бер, ике, өч – безнең кулда көч!» – дип һәркөн физзарядка ясыйм. Әйдә, бүген бергәләп кытай телендә саннарны өйрәнәбез дә спорт белән кытайча шөгыльләнә башлыйбыз! Вәт, кызык була...

Нариман ДИМӨХӘММӘТОВ

Алтынчы дәрес:

САННАР

一	[yī]	бер (и)
二	[èr]	ике (эр)
三	[sān]	өч (сань)
四	[sí]	дүрт (сы)
五	[wǔ]	биш (у)
六	[liù]	алты (лю)
七	[qī]	җиде (ци)
八	[bā]	сигез (ба)
九	[jiǔ]	тугыз (цзю)
十	[shí]	ун (ши)

十一	[shí yī]	унбер (ши и)
十二	[shí èr]	унике (ши эр)
二十	[èr shí]	егерме (эр ши)
三十	[sān shí]	утыз (сань ши)
四十五	[sì shí wǔ]	кырык биш (сы ши у)



Үрнәк буенча саннарны язып кара.

72

95

31

17

86

44


Тулырак күрсәтмәләр salavatkupere.com сайтында.
аяк
аяк
аяк өчен урын
Сәләвәт күпере
кул өчен урын
кул өчен урын
• Аюның гәүдә, аяк, кул өлешләрен кара сызыклар буенча кисеп ал.
• Пунктир сызыклар буенча бөклә.
• Ак өлешләрне ябыштырып гәүдәне, аяк, кулларны җый.
• Кул һәм аякларны тиешле урынга беркет.
кул
кул

Хәлил ШӘРИФ

АЮ МӘҖЛЕСЕ

Аю баласы беркөнне: «Әни, мин дусларымны кунакка чакырыйм әле», – диган. Әнисе риза булган, әмма: «Мин сезгә табын әзерләп китәрмен. Тик үзегезне бик әдәпле, яхшы тотыгыз», – дип кисәткән.

Аю баласы бик шатланган, тик «үзегезне әдәпле тотыгыз» дигән сүзләр аның күңеленә тынгылык бирмәгән. Чөнки аю баласы дусларының уңай яклары белән бергә кимчелекләрен дә бик яхшы белгән шул. Шуңа күрә ул, андый-мондый хәл булмагае дип, дусларын алдан ук кисәтеп куярга уйлаган.

Куян баласын мәҗлескә чакыргач: «Кишер өстәлдә дә мул булачак. Син, дускай, зинһар, бакчага кермә инде», – дип тә өстәгән. Тиен баласына: «Сиңа, дускай, анда чикләвек күп булачак, әмма аларның кабыклары белән идәнне чүпләмәссең инде», – дип кисәтүне кирәк тапкан. Бүре дустына: «Мәҗлестә сый һәркемгә җитәрлек булачак, син, дускай, башкаларның кисәгенә күз салмассың инде, ярыймы», – дип әйтүне хуп күргән. Керпегә ул: «Табын тыгыз булыр, ахры, син, дускай, уңга-сулга боргаланмыйча гына утырырсың инде, юкса күршеләреңнең ачуланулары бар», – дигән. Төлке баласына исә мәҗлес вакытын кичектереп әйткән. Чөнки ул, ничек чакырылуга карамастан, мәҗлесләргә һәрчак берничә сәгать алдан килгән, иң башта пешерү бүлмәсенә кергән, андагы тәм-томнардан авыз итеп йөргән, пешекчеләргә кирәкмәгән киңәшләрен биргән.

Менә билгеләнгән вакытка нәни киекләр мәҗлескә җыелганнар. Бары тик төлке баласы гына соңга калган. Табынга утырышканнар. Әмма... Йә, Алла, нинди мәҗлес булган бу: куян баласы аю баласына карарга да кыймыйча күзләрен гел аска яшереп утырган. Чөнки ул килешли бакчага кермичә түзә алмаган икән. Ә тиен баласы исә, чикләвек кабыгы идәнгә төшкән саен, аны өстәл астына чумып эзләгән. Бүре баласы үзе дә сизмәстән, усал карашын әле бер, әле икенче мәҗлестәше алдындагы сыйга юнәлткән. Керпе баласы, комачауламыйммы икән? – дип әле уңдагы, әле сулдагы күршесенә күз салган, шулай итеп, үзе дә сизмәстән, гел хәрәкәттә булган. Төлке баласы соңга калуына ачуы чыгып, үзе янындагыларга бәйләнгән, кирәксә дә, кирәкмәсә дә алар янында әйләнгән.



Кунаклар киткәч, аю баласы өй эчен тәртипкә китергән, ә әнисе кайткач түкми-чәчми барсын да аңа җиткергән.

– Һм-м... Әйе, бәхәссез, синең дусларың кунак булу, табында утыру кагыйдәләрен бик үк саклап тормаганнар, – дигән әни аю. – Әмма бит син, улым, аларны үзең дә моңа этәргәнсең, урынсыз киңәшләрең белән башта ук башларын бутагансың.

Шуннан соң аю баласы бик җитди уйланган һәм болардан үзенә тиешле сабак алган, ди.

«САЛАВАТ КҮПЕРЕ» ЖУРНАЛЫНА ЯЗЫЛУНЫҢ БЕРНИЧӘ ЫСУЛЫ БАР:

1 Россиянең һәм Татарстанның барлык почта бүлекләрендә. Моның өчен сезгә иң якын почта бүлегенә барып, квитанция тутырырга кирәк (биредә басманың исемен – «Салават купере», индексын – П2339, ничә айга язылуыгызны, төгәл индекс, адрес һәм исем-фамилиягезне язу сорала). Әлеге ысул Татарстанда яшәүчеләргә кагыла. Ә Россиянең башка төбәкләрендә яшәүчеләр «Роспечать» каталогы аша 73953 индексы белән яздыра ала. Шулай итеп, яраткан «Салават күпере» сез күрсәткән почта әрҗәсенә килеп торачак.

2 www.uslugi.tatarstan.ru порталы аша электрон язылу. Шәхси кабинетыгызга язылу теркәлгән дигән хәбәр килә һәм сез билгеләгән вакыттан журнал өегезгә килеп җитәчәк.

3 Pressa.ru яки tatpodpiska.ru сайтлары аша. Теркәлгән вакытта язып калдырган электрон адреска журнал pdf-форматында киләчәк.

ПОЧТА РОССИИ

ФГУП «Почта России» ф. СП-1

Бланк заказа периодических изданий

Абонемент на ☐ Газету ☐ Журнал (Индекс издания)

Наименование издания — Кол-во

На 20__ г. по месяцам: 1 2 3 4 5 6 7 8 9 10 11 12

Кому ФИО, наименование юридического лица

Куда

Индекс +7

- - - линия среза - - -

Доставочная карточка на ☐ Газету ☐ Журнал (Индекс издания) ПВ место литер

Наименование издания

Стоимость				Количество комплектов
подписки	руб.	коп.		
контактная	руб.	коп.		
переадресовки	руб.	коп.		

На 20__ г. по месяцам: 1 2 3 4 5 6 7 8 9 10 11 12

Индекс +7

город/село

область

район

улица дом

корпус квартира

ФИО

ЯЗЫЛУ 18 НЧЕ ИЮНЬГӘ КАДӘР БАРА!



V ХАЛЫКАРА ЯШЬЛӘР УКУ-УКЫТУ
СӘЛӘТ ФОРУМЫ
9-14 ИЮЛЬ 2016

«БӘЛӘКӘЧ»



ПРОГРАММАДА:

«БЕЛӘСЕМ КИЛӘ» КҮНЕГҮЛӘРЕ
«АСТАН КАРАШ» ВИДЕО-РУБРИКАСЫ
«ГҮЗӘЛ БАНУ БЕЛӘН РӘСЕМ ЯСЫЙБЫЗ»
АКВАГРИМ
КУРЧАК ТЕАТРЫ
КОНКУРСЛАР ҺӘМ КҮРГӘЗМӘЛӘР
РАБИТ БАТУЛЛА ҺӘМ ӘДИП ӘЛМИР БЕЛӘН «ӘКИЯТ УКЫЙБЫЗ»
ЯШЬ ӘНИЛӘР ӨЧЕН ТРЕНИНГЛАР
БАЛАЛАР АЭРОБИКАСЫ ҺӘМ ЙОГА











«БӘЛӘКӘЧ»ТӘ ОЧРАШЫРБЫЗ!

РЕКЛАМА 0+



№6 (315) – 2016

Журнал 1990 елның
март аеннан бирле чыга.
Журнал выходит
с марта 1990 года.

Директор
Зиннур ХӨСНИЯР
(Зиннур Зыятдин улы ХӨСНЕТДИНОВ)

Баш мөхәррир
Зилә ЯЗ
(Зилә Зиннур кызы ХӨСНЕТДИНОВА)

Баш мөхәррир урынбасары
Гүзәл ЗИННӘТУЛЛИНА

Мөхәррирләр
Гөлназ ЯРМИЕВА
Алсу НИЗАМИЕВА

Баш рәссам
Әлфия ЙОСЫПОВА

Компьютер дизайны
Мөнирә КУЗИЕВА

0+ Мәктәпкәчә яшьтәге һәм кече яшьтәге мәктәп балалары өчен.

«Салават күпере» журналының компьютер үзәгендә җыелды һәм төсләргә бүленде.

Басарга кул куелды 21.05.16 ел.
Кәгазь форматы 60x90 1/8.
Гарнитура – PT Sans.
Офсет ысулы белән басыла.
Заказ: М-1266. Тираж: 10250 данә.
Килгән хатлар, кульязмалар һәм рәсемнәр рецензияләнми, авторларга кире кайтарылмый.

Почта гаебе белән журнал өегезгә килеп җитмәсә, түбәндәге телефон белән газета-журналлар экспедициясенә шалтырата аласыз: (843) 562-10-66.



Журналны гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» АҖ.

Татарстан республикасы матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәмендә чыгарыла.

Бәясе ирекле. Индекс: П2339.

Тышлыкта Кира Хәлимуллина, 3 яшь 11 ай, Казан.

Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ, 420097, Казан, Академическая ур., 2 й.
Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2 й., 10 кат.
Тел.: (843) 519-45-89.
E-mail: salavatkupere@mail.ru
Сайт: www.salavatkupere.com

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча федераль хезмәт тарафыннан ФС77-54277 номеры белән 2013 елның 24 маенда теркәлде.

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
Адресы: Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2 й.

0+

РЕКЛАМА

ВЕСЕЛОЕ ЛЕТО В АКВАПАРКЕ



- 50 АТТРАКЦИОНОВ
- ВОЛНОВОЙ БАССЕЙН
- СПА-КОМПЛЕКС
- ДЕТСКИЙ ПИРАТСКИЙ ФОРТ
- ДЕТСКИЕ ДНИ РОЖДЕНИЯ
- БИСТРО, АКВАБАР



КАЗАНЬ, АМИРХАНА, 1, WWW.KAZANRIVIERA.RU

526·57·57